ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

03.06.2019

№ 892

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2020 елларга Алабуга муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 5 декабрендәге 1515 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2012 нче елның 19 нчы декрабендәге 1666 нчы санлы Указы белән расланган 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең дәүләт милли сәясәте Стратегиясен исәпкә алып, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль программаларны эшләү, гамәлгә ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»гы 2014 нче елның 9 нчы июлендәге 765 нче санлы карарын гамәлгә ашыру максатыннан, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2017-2020 елларга Алабуга муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 5 декабрендәге 1515 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2017-2021 елларга Алабуга муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын раслау турында».

2. «2017– 2021 елларга Алабуга муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен гамәлгә ашыру» муниципаль программасын яңа редакциядә расларга (алга таба – Программа).

3. Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Э.И. Садыйкова) муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруда бюджет ассигнованиеләрен алдан карап эш итүне тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин